# Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карары

Азнакай шәһәре №193-29 2018 елның "28" маеннан

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2006 елның 23 гыйнварындагы 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2008 елның 31 октябрендәге 217-30 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 121-18 номерлы, 2013 елның 26 апрелендәге 228-34 номерлы, 2014 елның 29 гыйнварендәге 284-40 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 351-51 номерлы, 2015 елның 25 августындагы 385-55 номерлы, 2017 елның 13 декабрендәге 156-23 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге 299-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән һәм җирле үзидарә турындагы законнарга туры китерү максатларында,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2006 елның 23 гыйнварындагы 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты турында (2008 елның 31 октябрендәге 217-30 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 121-18 номерлы, 2013 елның 26 апрелендәге 228-34 номерлы, 2014 елның 29 гыйнварендәге 284-40 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 351-51 номерлы, 2015 елның 25 августындагы 385-55 номерлы, 2017 елның 13 декабрендәге 156-23 номерлы карарлар редакциясендә) Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 3.2 пунктта:

- уникенче абзацта «аларның гомеренең һәм сәламәтлегенең иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп» сүзләрен өстәргә;

- унөченче абзацта «медицина ярдәме» сүзләрен өстәргә;

- кырык дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча федераль законнар нигезендә контрольдә тоту;»;

1.2. 4.1 пунктындагы «б» пунктчасында «план проектларына» сүзләрен «стратегия» сүзенә алмаштырырга;

1.3. 4.3 пунктындагы «а» пунктчасында «икътисадый һәм социаль план» сүзләрен «социаль-икътисадый стратегия» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 5.7 пунктта:

- бишенче абзацта «Башкарма комитет, урынбасарлар» сүзләреннән соң «җитәкче» сүзен өстәргә;

- сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль районның җирле бюджеты проектын һәм аның үтәлеше турында хисап, муниципаль районның социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслауга муниципаль районның вәкиллекле органына әзерләүне оештыра һәм кертә;».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин